Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәтү бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

# Ислам нуры

№ 3 (631) 13 февраль, 2017 ел (1438, Җөмәдел-әүвәл) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

12+

## Тарихи визит



Мәгълүм булганча, Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннеханов җитәкчелегендәге Татарстан делегациясе Согуд Гарәбстанына эшлекле сәфәр кылды. Делегация составында республиканың төрле тармак җитәкчеләре, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, РИИ ректоры Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшин һ.б. бар иде.

7 февральдә Рөстәм Миңнеханов Согуд Гарәбстанына рәсми визиты кысаларында Ике Изге урын саклаучысы, Мәликзадә Солтан ибн Салман ибн Габдел-Газиз әл-Согуд белән очрашты. Әңгәмә вакытында Татарстан Республикасы Президенты Мәлик Салман бин Абдел Азиз Эль-Согудны республиканың хәзерге икътисади хәле, сәнәгать үсешенең төп юнәлешләре, Ислам кануннарына туры килгән партнерлык банкингы системасын кертү турында сөйләде. Рөстәм Миңнеханов Согуд Гарәбстаны эшлекле даирә вәкилләрен кызыксындыра алырлык Татарстанда тормышка ашырыла торган инвестиция проектларына аерым тукталды. Ул шулай ук Россия Федерациясе Президенты тапшырган йөкләмә буенча “Россия — Ислам дөньясы” стратегик караш төркеме рәисе булуын, аның эшчәнлегендә Согуд Гарәбстаны вәкилләре дә катнашуын искәртте.

Очрашуның азагында Рөстәм Миңнеханов Мәликзадә Солтан ибн Салман ибн Габдел-Газиз әл-Согудка кунакчыллыгы өчен рәхмәт белдерде һәм Татарстан Республикасына кунакка чакырды.

8 февральдә Татарстан Президенты кече хаҗ кылды. Татарстан вәкилләре Согуд Гарәбстанының бары шәрәфле кунаклары гына керә торган Кәгъбә эченә дә керделәр.

**Рәсемдә:** Татарстан Президенты Рөстәм Миннеханов ихрамда Кәгъбәтуллаһ ишеге янында; арткы планда мөфти Камил хәзрәт.

## Чаллы имамнарының чираттагы җыелышы



30 гыйнварда Чаллы шәһәре имамнарының чираттагы җыелышы булды. Ул шәһәр территориясендә террорчылыкны кисәтү мәсьәләсе буенча әңгәмәдән башланды. Аны шәһәр Эчке эшләр идарәсе хезмәткәрләре үткәрделәр. Имамнар шулай ук ошбу тема буенча Эчке эшләр идарәсе тәкъдим иткән видеороликлар белән таныштылар.



Икенче көн тәртибе буенча балаларның ел саен язгы каникул чорында Чаллыда үтә торган традицион Коръән уку бәйгесенә әзерлек мәсьәләсе тикшерелде. Быел ул 22 нче мәртәбә уздырыла. Җыелыш фикер алышканнан соң бәйге шартларын раслады. Бәйгене 22 мартта уздырырга карар ителде.

Җыелышта шулай ук яшьләр белән эшләүне көчәйтү мәсьәләсе кабат күтәрелде. Мәчетләрдә яшьләр бүлекләрен формалаштыру төгәлләнгәч аларның җитәкчеләре белән киләчәк бурычларны билгеләү өчен җыелыш уздырырга килешенде.

## Аксакаллар тәҗрибә уртаклашты

2 февральдә Чаллы мөхтәсибәте каршында оешкан Аксакаллар шурасы үзенең бер еллык эшчәнлегенә йомгак ясады. Җыелыш барышында мәчетләр каршында эшләгән Аксакаллар шурасы рәисләре үз эшчәнлекләре хакында мәгълүматлар бирделәр. Мөхтәсибәт каршындагы Аксакаллар шурасы рәисе “Туфан” мәчете имам-хатыйбы (җыелыш шушы мәчеттә узды) Равил хәзрәт Нуруллин белдерүенчә, бер ел элек төп бурыч булып барлык мәчетләр каршында да Аксакаллар шурасын оештыру бурычы торган. Һәм ул уңышлы үтәлгән. Икенче бурыч — эшне планлы оештыру, мәчет картлары дәрәҗәсен күтәрү. “Без имамнар җитәкчелегендә имамнар рөхсәте белән эшләргә тиеш. Бурычыбыз имамнарга дин-тәрбия эшләрендә булышлык күрсәтү,”- диде Равил хәзрәт үзенең керeш сүзендә. Аксакаллар шурасы рәисләре хәбәр иткәнчә, мәчетләрдә бу юнәлештә инде эшләр шактый уңышлы башланган. Мәсәлән, “Ихлас” мәчетендә яшьләр мәчет картларын хөрмәтләү мәҗлесе уздырганнар, мәҗлестән соң автомашиналарында аларны өйләренә алып кайтып куйганнар. Мәчет картлары өчен Коръән мәҗлесләрен уздыру буенча укулар оештырылган. Үткән дәресләрнең берсенә анда белемнәрен күтәрүче бабайлар вәгазь язып алып килгәннәр. Мәчет имам-хатыйбы аларның вәгазьләреннән бик канәгать калган. “Кәүсәр” мәчетендә бабайлар эчке тәртипне гореф-гадәтләргә якынайту буенча эшли башлаганнар. “Туфан” мәчете картлары мәчет тарихын барлау эшенә тотынган. “Тәүбә” мәчетендә җәмагать көче белән мәчеткә агымдагы ремонт бушлай үткәрелгән, атна саен бирегә хәйрия ашлары оештырыла. Барлык мәчетләрдә дә диярлек мәхәллә территориясендә яшәүче мохтаҗ кешеләрне ачыклау буенча эш башланган, аларның бер өлешенә матди ярдәм күрсәтелгән.



Аксакаллар шурасы рәисләренең шундый киңәшмәләрен квартал саен үткәреп барырга килешенде. Аларда башкарылган эшләргә нәтиҗә ясалачак, эш тәҗрибәсе белән уртаклашу булачак.

Аксакаллар җыелышында шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин катнашты һәм чыгыш ясады. Җыелыш ахырында Аксакаллар хөрмәтенә аш мәҗлесе уздырылды.

**Рәсемдә:** җыелыштан күренеш.

# Фәкыйрьлек: кесә юкалыгымы, әллә күңел тарлыгымы?

Соңгы вакытта күп кенә кешеләрнең тормыштан зарлану, бөтен кешеләрне сүгү яраткан шөгыльгә әйләнеп бара. Кайбер авыл кешесе көненә бер мәртәбә күршесе белән көрәшеп, бераз авыл сәвитен, аннан район башлыгын, республика җитәкчесен, ил патшасын чәйнәп алмаса, йокысы йокы булмый. Әлбәттә, бөтен кайгы-хәсрәтләребезнең башында торучы Обаманы да читтә калдыру ярамый. Чыннан да «тегесе җитми, монысы җитми» дип зарланырга яратсак та, соңгы егерме ел эчендә яшәгән тормышларыбыз бик матурланды, дөньяларыбыз шактый киңәйде. Әбием исән чакта: «Ий, улым, сез бәхетле балалар, мин мондый рәхәт тормышны күрермен дип хыялланмадым да», - дип еш кабатлый иде. Шулай да, дөньяның матурлыгына тиз күнегәбез. Киң-киң атлап барган юлларыбыз бераз тараеп китсә, шундук күңелгә борчу төшә, йокы кача. Хәер, кешелек һәрвакыт муллыкка омтылган, хәерчелектән куркып яшәгән.

Бервакыт, кешеләр мохтаҗлык турында гәп корып утырганда алар янына пәйгамбәребез килә һәм: «Сез фәкыйрьлектән куркасыз мени? Аллаһы белән ант итеп әйтәм, дөнья сезнең өстегезгә койма яңгыр кебек явачак. Йөрәгегезне шушы дөнья малы гына хак юлдан аздырачак. Мин сезне ачык аклыкта калдырдым, аның төне дә, көне дә бер тигез ачык булды», - дип әйтә (Ибн Мәҗәһ риваяте).

**Имам Мәнәви әйтүенчә:** *«Әлеге хәдистә пәйгамбәребездән өммәтенә сөенеч килә, Аллаһы Тәгалә бу өммәткә фәкыйрьлектән соң байлык бирәчәк. Ләкин, өммәте шушы мал сәбәпле Раббысына гыйбадәт кылуны онытачак. Дөньяны ярату сәбәпле, туры юлдан баручы калебләр дә тайпылачак, һидаятьтән адашачак. Дөнья аларның фетнәсе булачак».*

Аллаһының илчесе бүгенге көн турында әйткән кебек. Чыннан да, дөнья безгә капкаларын киң итеп ачты, мул яңгырлар булып өстебезгә ява.

**Сөбханәллаһ, нинди йортларда яшибез?** Авылларда кайберләребезнең йортлары зиннәтле патша сарайлары кебек. Ярый ла гаиләдә 2-3 бала булса. Элек дүрт почмаклы өйдә мич тирәли тезелешеп 5-6 бала үстергәннәр. Әби-бабайга да урын табылган. Сарык-бәрәннәре дә чабышкан. Мич артында каз бәбкәләрен чыгарган. Ә хәзер кайбер йортларда бер бала бүлмәдән бүлмәгә кереп, бичара адашып йөри. Минем бабай сугыштан соң әбине хатын итеп алып кайткач, алар әтисенең мунчасында яшәгәннәр. «Бөтен булган акчама самавыр алдым, шуннан эчкән чәйнең тәме һаман авызымда әле», - дип сөйли иде. Бүген кайбер никахларда кода-кодагыйлар узыша-узыша яшьләрне муллыкка күмәләр. Егет ягы торып шәһәрдән фатирын бүләк итә, кыз ягы яңа машина ачкычын тапшыра. Шулай, заманалар башка хәзер.

**Ә нинди атларда йөрибез?** Без кечкенә вакытта, күрше тирәдәге абыйлар: «Жигули москвичтан җылырак», - диләр иде. Хәзер, атның җылы мичe генә түгел, яхшы суыткычы да булырга тиеш. Бер дустым тимер атын алыштырырга йөри дә, аннан: «Әле кайчан гына алган идең бит, ник тагын алыштырырга булдың?» - дип сорадым. Ул: «Минем утыргычы җылыта торган гына, ә хәзергеләренең астан суытып тора торганы да бар, шундыйны алам әле», - ди.

**Ә нинди киемнәр киябез?** Бабай: «Без үскәндә төпсез киндер ыштан була иде, хәзер балаларыгызның киемнәрен ничек кидертеп бететергә белмисез», - дип гаҗәпләнә иде. Чыннан да, берәр җиргә барасы булса, зур проблема килеп туа: нәрсә киярге? Әлеге сорау киярену булмаганнан түгел, киресенчә, киемең артык күп булганнан килеп чыга. Әле ирләргә барыбер җиңелрәк, менә абыстайларыбыз иза чигәләр. Сөбханәллаһ, пәйгамбәр вакытында кайбер кешеләрнең алмашка киемнәре булмаганлыктан, алар күлмәкләрен югач, кипкәнен көтеп өйләрендә утырганнар.

**Ә нинди табыннардан ашыйбыз?** Безнең авылдә бер мәчетнең хәзрәте сөйли иде: «Кибеткә товар бушатышканы өчен ике малайга берешәр прәник бирделәр дә, кибет артына утырып ашадык. Берсе сөенеченнән: «Кара әле, Сталин да болай ашамагандыр име?» - дип әйтте ди. Бүгенге табыннарыбыз, сөбханәллаһ, патшаныкыннан ким түгел. Кайчак гади генә кешеләргә ашка барсаң да, табын өстендә аш тәлинкәсе куярга урын юк. 30-40 ир заты ике сәгать ашап та, табында ризык бетү түгел, кимеми дә.

**Дөнья матурланган саен күңелне әсир итә.**

Дөньябыз шулкадәр матур, якты һәм киң. Бу хакта бер кыйсса искә төшә, бер егет төш күрә икән: килеп кергән бер урманга, агачлар өстеннән шулкадәр моңлы итеп бер кош сайрый. Егет кошның үзен дә күрү теләге белән тавыш ишетелгән агачның астына ук килеп баса һәм күзе белән кошчыкны эзләргә тотына. Әмма, кош аның йөзенә йомышын үтәп куя. Егет битен нәҗестән чистартып, тәмам күңелсезләнеп китеп бара. Күп тә үтми аның күзе бер бик матур кызга төшә. Кызның чибәрлегеннән аның күңеле әсир кала. Егет якыннанрак күрү өчен аңа таба юнәлә, ләкин кыз аннан ерагаерга тотына. Егет тизлеген арттыра, кыз тагын да ерагая, ахыр чиктә егет урман эченә кереп адаша. Йокысыннан уянгач ул бер төш юраучы бабайга китә, бәйнә-бәйнә төшен сөйләп бирә. Бабай аңа: «Моңлы итеп сайраучы кош — ахырзаман галимнәре. Алар бик матур сөйлиләр, якынрык килеп карасаң, эчләре тулы тизәк булганын беләсең. Ә теге матур кыз, ул синең яшәгән тормышың. Дөньяны куам дип артыннан чабасың, ул синнән чаба. Тизлегеңне арттырасың, ул тагын да тизәя. Ахыр-чиктә аны да куып җитә алмыйсың, кереп адашасың да».

Кызның матурлыгы белән исәрләнгән егеттәй дөнья артыннан чабабыз. Ул да үзенә омтылучыларны сизеп, тагын да зиннәтләнә, күңелебезнең эченәрәк керә, тагын да нечкәрәк кылларына үтә. Дөньяга гашыйк булганнарның иң курыкканы — аны югалту, дөнья малын кулдан ычкындыру булып тора. Кешенең коты имансызлык, әхлаксызлык, оятсызлык кебек куркыныч төшенчәләрдән түгел, бәлки, фәкыйрьлек, хәерчелек, кризис сүзләреннән күбрәк оча.

Игътибар итегезче, бер урынга җыелсак, күбрәк нәрсә турында сөйләшәбез? Бала тәрбиясе, ничек милләтнең узаңын, әхлагын, ана телен саклап калыргамы? «Это вы о чем, хазратушка? Нинди милләт, нинди үзаң? Без әле дөнья куабыз, дөньяны бүлешәбез». Шунысы кызык, кемдә күпме дөнья булуына карап, һәркайсы үз баткаклыгына чума. Әби-бабайлар җыелышсалар пенсия сөйләшәләр, заводта эшләүчеләр тәмәке тарткан арада начальствоның күпме урлашканын «чәйнәшеп» алалар. Бервакыт, дустым Мәскәүгә ифтар ашына чакыргач, табынга башкаланың хәлле генә егетләре җыелыштылар. Әйдә, хәзрәт, безне бераз вәгазьләп ал, дигәч, аларны: «Дөньяга алданмагыз, дөнья малы кесәгездә булсын, күңелегезгә кермәсен. Дөнья килә дә китә, ахирәт мәңгелек», - дип вәгазь сөйләдем. Унбиш минут сабыр иткәннән соң бер егет: «Ишеттегезме әле, «Башнефть» акцияларен сата икән», - дип әйтүе булды, бераз гына дөньядан чыгып кергән егетләрне дөнья баткагы үзенең капшавычлары белән янә эләктереп, кире үзенә тартып алды.

Әлхәмдүлилләһ, Раббыбыз безне дөнья һәм нәфесебез белән ялгызын калдырмады. Ул безгә нәфескә каршы торучы зур көч дин иңдерде. Пәйгамбәребез: **«Мин сезне ачык аклыкта калдырдым, аның төне дә, көне дә бер тигез ачык булды»**, - диде.

Әгәр кеше Аллаһының динен өйрәнсә, күңеле түрендәге изге урынны миненә түгел, диненә бирсә, тормышта нинди генә хәл булса да, нинди генә михнәткә, бәлагә тарыса да, чыгу юлын табачак, туры юлда калачак.

**Рухи байлыгыбыз китә!**

Әгәр кешеләр фәкыйрьлектән курыксалар, байлыгым китә, - дип ут эчендә янсалар, минем җир өстендә тамыр җәюче тагын да зур фәкыйрьлекне искә төшерәсем килә. Бервакыт, Әбү Зәр исемле сәхабәдән пәйгамбәребез: «Әбү Зәр, син малның күп булуын байлык дип уйлыйсыңмы?» - дип сорады. Әбүзәр: «Әйе, Аллаһының илчесе», - диде. Пәйгамбәр: «Ә малның аз булуын фәкыйрьлек дип күрәсеңме?» - диде. Ул: «Әйе, Аллаһының илчесе», - диде.

Чыннан да, без кешеләр: зур йортта, затлы атта йөрүчегә карап: «Бигрәк бай кеше бу», - дип уйлыйбыз. Пәйгамбәр исә: **«Байлык — фәкать күңел байлыгы, фәкыйрьлек — күңел фәкыйрьлеге генә»,** - диде (Ибн Хиббән).

Чыннан да, күңеле бай булган адәмнең кесәсе юка булса да, ул бай кеше. Ул Раббысының тәкъдиренә риза, үз насыйбыннан канәгать. Күңеле фәкыйрь булган кешегә әллә никадәр киң маллар бирелсә дә, ул аның шатлыгын тоя да, күрә дә алмый. Кешенең бөтен шатлыгы да, борчу-хәсрәтләре дә күңел халәтенә кайта. Кайвакыт, ипи-сөтенә, дару алырына акча җиткерә алмый зар кылучы әби-бабайларга: әйдәгез мәчеткә йөрегез әле, - дип әйтәсе килә. Кемдер: «Әллә мәчеттә акча бирәләрме?» - дип сорар. Мин мәчетләргә йөрүче, намаз укучы әби-бабайларыбызга карап сокланам. Сөбханәллаһ, алар да шул пенсия акчаларына яшиләр(хөкүмәт мәчеткә йөргән өчен пенсияне арттырмый), бала-оныкларына да ярдәм итәләр, әле хаҗга да барырга акча табалар. Бер мәртәбә түгел, кайберләре 3-4 мәртәбә хаҗ кылганнар. Әле мәчет-мәдрәсәләргә дә ярдәм итеп торалар. Һәр нәрсәнең бәрәкәте кирәк. Бәрәкәт дигәне аз малны да күп итә, бәрәкәтсезлек күп малны да юк итә.

Дөнья тормышын шулкадәр яратабыз. Аллаһ күбрәк бирсә күңелләребез күтәрелә, бераз кысып куйса күңелсезләнергә тотынабыз. Әгәр бер кешегә күп итеп мал бирелсә, кулындагы ризыгы киңәйсә, бу Аллаһының аңа булган рәхмәте дип уйлыйбыз. Шулук вакытта, Аллаһ берәүнең дөньясын киметсә, бу Аллаһы Тәгаләнең аны кимсетүе дибез. Аллаһы Тәгалә әйтте: **"Әгәр Раббысы кешегә сынау буларак Үз юмартлыгын күрсәтсә, нигъмәтләрен иңдерсә, ул: "Раббым мине хөрмәтләде",** - дип әйтә. Әгәр сынау өчен аның ризыгын киметсә, ул: "Раббым мине кимсетте", - дия".

Кызганыч, күпләр шулай уйлыйлар. Ләкин, Аллаһы Тәгаләнең кемнедер малга күмгәндә һәм кемнедер ризыгын киметкәндә без күргәннән тирәнрәк хикмәтләре ятуын онытмыйк. Раббыбыз, киләсе аятендә: **"Юк, шул"**, - дип әйтә ("Фәҗер" сүрәсе, 15-17 аятьләр). Хакыйкать алар уйлаганча гына түгел. Әгәр Аллаһының бәндәсенә булган мәхәббәте һәм рәхмәте малның күплеге белән үлчәнсә, ни өчен Аның иң яраткан бәндәсе пәйгамбәребезнең өендә вакыт-вакыт ай буена кайнар ризык пешерергә мөмкинлеге булмаган. Ни өчен Аллаһының каргышында булган Фиргавенне Ул мал-мөлкәткә, киң ризыкка күмгән? Аллаһы Тәгалә бер бәндәсен киң мөлкәт биреп сынаса, икенчесенең ризыгын киметеп сыный. Гомумән, без яшәгән дөнья үзе бер зур имтихан бүлмәсе — аудитория. Кешеләрнең кулларына сораулар язылган кәгазьләр тапшырыла, берәү дә алдан нинди сорау эләгәсен белми. Әмма, һәркем имтиханда җиңел сорау бирелсә ярар иде дип теләп тора. Хикмәт иясе Аллаһ берәүне авырлык белән, икенчене җиңеллек белән сыный. Берәүнең имтихан билетында байлык сынавы, икенчекендә — мохтаҗлык чыга. Берәүдә — саулык, икенчедә — сырхау. Берәүдә — борчу-мәшәкать, икенчедә — иминлек. Берәүгә Раббы балалар биреп сынаса, икенчене баласызлык белән сыный. Төп хикмәт — кемгә нинди сорау чыгуда түгел, ә ул сорауга дөрес итеп җавап бирә алуда. Аллаһы Тәгаләдән бәндәгә бер нигъмәт килсә, аннан шөкер-рәхмәт китәргә, авырлык килсә, ул аны сабырлык белән кайтарырга тиеш. Тормышта кемгә нәрсә яхшы булуын имтихан соравына дөрес итеп җаваб бирү билгели. Күпме кешеләр мохтаҗлыкта яшәп тә, үзләренең намусларын югалтмыйлар, кыйбладан тайпылмыйлар. Ә күпме кешеләр байлык, матур тормыш күреп шашыналар, бөтенләй кешелеклелек сыйфатларын югалталар.

Аллаһыны оныттыручы саулыгыңа карый, Аны исеңә төшерүче авыруың хәерлерәк, - дигән борыңгылар. Күпме кеше михнәткә түзә, әмма рәхәткә түзә алмый. Пәйгамбәребез Аллаһы Тәгаләдән кешегә зыян китерүче байлыктан да, мохтаҗлыктан да сыенып шушы доганы кыла торган булган: ***"Йә, Аллаһ, Сиңа байлык фетнәсеннән һәм фәкыйрьлек фетнәсеннән сыенам"***.

Шуңа күрә, Аллаһының сынауларын дөрес итеп кабул итү һәм дөрес җавап бирү өчен кешегә иман, дини белем кирәк. Пәйгамбәребез: ***"Иман иясенең хәле гаҗәеп, андый хәл башка һичкемдә юк. Аның өчен һәрнәрсә хәерле. Әгәр аңа шатлык килсә, ул шөкер итә һәм бу аңа хәерлелек булып кайта. Әгәр аңа зыян-зарар килсә, ул сабыр итә. Бу да аңа хәерлелек булып әверелә", - диде().*** Сөбханәллаһ, иман иясе шатлык килгәндә шөкер итеп, авырлык килгәндә сабыр итеп һәр сынаудан да җиңүче булып чыга.

Аллаһ биргән нигъмәтләргә шөкер итик, әби-бабайларыбыз күргән михнәтләрне, алар кичергән ачлык-ялангачлыктан гыйбрәт, дәрес алыйк. Аларның күбесе бездән иманлырак булдылар, әмма күпме авырлыкларны үз башларыннан кичерделәр.

Риза хәзрәтләре Рәсәй мөфтие, милләтебезнең олуг шәхесе булып та, аңа "халык дошманы" дип кибеттән ипи сатмаганнар. Ул спекулянтлардан икеләтә, өчләтә бәяга ипи алып гаиләсен туйдырган. 1933 елда аның Финляндиядәге дустыннан күчтәнәчләр белән посылка килеп төшә. Риза хәзрәт аңа рәхмәт әйтеп язган хатында шундый юллар була: "Почтадан хәбәр кәгазе килгәч, посылканың авыр икәнен белдем. Элегрәк булса тартмада китаплар булса ярар иде дип теләр идем, ләкин хәзер ризык булса ярар иде дип өметләндем". Шул күчтәнәчләр белән Риза хәзрәтләре гаеттә балаларын сөендерә. Сөбханәллаһ, кайчандыр, ата-ана баласына бәйрәмдә кәнфит-прәниген алып бирә алса, бу барысы өчен шатлык булган. Бүген кайбер балалар аталарына вакытында җиденче айфон алып бирә алмаганга үпкәлиләр.

Без бүген гаеттә балаларга ризыклар алу өчен бөтенләй борчылмыйбыз, чөнки ел дәверендә гаеттә кебек ашыйбыз. Без дә бүген туйганчы ак ипи ашый алмыйбыз, чөнки "ипи симертә" дибез. Без дә балаларга кибеттән шоколад конфетларны еш алмыйбыз, анда консервантлар бар дибез. Күпләр прәник-печеньесын да сирәк ашыйлар, ләкин булмаганга түгел, анда маргарин бар диләр. Муллык дигәне шушы була инде.

Ий, Раббым, синең җирең буйлап йөрибез, кояшың астында яшибез. Синең ризыкларыңны ашыйбыз, суларыңны эчәбез, һаваңны сулыйбыз. Җир өстендә күпме гөнаһлар кылабыз, Сиңа рәхмәт тә әйтергә онытабыз. Без гөнаһлы бәндәләреңне гафу ит. Безгә Үзеңнең сый-хөрмәтләреңне күрә белеп, шөкер кылып яшәүләрне насыйп әйлә.

**Йосыф хәзрәт Дәүләтшин.**

*Редакция почтасыннан*

## Бергә булыйк, бердәм булыйк!

Нинди рәхәт, иркен заманда яшибез: Аллаһының кушканнарын, пәйгамбәребез (с.г.в.) сөннәтен һәм гасырлар аша әби-бабаларыбыздан безгә килеп ирешкән дини йолаларны үтәргә бөтен мөмкинлекләр бар. Дини карашлар өчен эзәрлекләү, көчләп чукындыру куркыныч әкият кебек тоела.

Ел башында кулыма Тәтеш районы музее хезмәткәрләренең төбәк тарихын өйрәнү буенча язылган хезмәте килеп кергән иде. Бу китапта Кайбыч, Апас, Тәтеш төбәгендә урыс чиркәве тарафыннан оештырылган көчләп чукындыру вакыйгалары тасвирланган. Христиан диненә күчмәс өчен халык авылы-авылы белән урманнарга качып, землянкаларда яшәргә мәҗбүр булган. Буйсынмаган авылларга гаскәр кертеп, ирләрен каторгага сөреп, хатын-кызларны урыс авылларындагы мужикларга "бүләк иткәннәр." Арба тәгәрмәче озынлыгындагы ир-балаларны әти-әниләре күз алдында бәкедә чумдырып чукындыру вакытында терелләй боз астына агызып җибәргәннәр. "Өнем өчен түгел, көнем өчен,"- дип, имана җире алыр өчен, салым түләмәс өчен телдән генә христиан диненә күчүчеләр булган, билгеле. Чистай өязендәге канлы вакыйгалар Гаяз Исхакыйның "Зөләйха" әсәрендә ачык тасвирлана. Шул исемдәге спектакльне дә тетрәнмичә карау мөмкин түгел. Татарны кылыч белән сындырып булмаячагын аңлаган миссионер Ильминский: "Татарны хәрам кулланырга өйрәтеп, мәгарифен корытып, исламның фәлсәфи тәгълиматын җимереп, аны дини йолалар үтәүгә генә әйләндерергә кирәк,"- дип трактат язган. Шуннан соң татар авыллары лавкасына мичкәләп исерткеч эчемлек кайтарыла. Революциядән соң динне эзәрлекләү чорында эчүчелек бигрәк тә киң таралды, кәләпүшле татар агае да, һәм хәтта татар хатын-кызлары да эчү буенча урыстан калышмагандыр. Икенчедән, Ильминский тарафдарлары хәзер дә исән, ахры: мәктәпләр ябыла, татар телендә сөйләшүчеләр кими. Ислам дине дә күпләрнең исенә дини йолалар - исем кушу, никах уку, мәет җирләүне башкарганда гына төшә. Татарстанда 2 меңгә якын мәчетләр бар, ә йөрүчесе аз. Белемле хәзрәтләр җитми, 80 еллап дәһрилек чорында яшәгән халыкны Исламга кире кайтару бик кыен. Югыйсә, дини белем алырга бөтен мөмкинлекләр бар. Иманлы кеше әхлакле була, җәмгыятьтә вәзгыять тә яхшыра.

Газиз милләттәшләрем, мөселманлыгыбызны җуймыйк, бергә һәм бердәм булыйк!

**Рәмзия Шәймөхәммәтова**
**Әгерҗе шәһәре.**

## "Ислам нуры"н көтеп алабыз

Әссәләмүгаләйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһ, "Ислам нуры" редакциясе хезмәткәрләре!

Мин Башкортстан республикасы Борай районы Иске Бикмәт авылыннан хат язучы Наилә абыстай. Авылыбызда мәчет эшләп килә. Менә 12 ел тулып китте. Мәчетебез һәркөн ачык: җомга, ураза, корбан гаетләре, тәрәвих намазлары, Мәүлид бәйрәмнәре бик матур үтә. "Ислам нуры" газетасын көтеп алабыз. Андагы вәгазьләрне Коръән ашларында, мәчетебездә кулланабыз. Татар телендә чыккан газета буларак, ул безгә бик кадерле. Мәҗлесләрдә авыл халкына таратабыз. Безнең авылдагы һәм районлагы кешеләр татар һәм башкорт милләтеннән. Татарча укыйбыз, сөйләшәбез. Бу газетада намаз вакытлары да бирелә. Намаз укучыга ул бик кирәк. Авыл халкына алдырырга тәкъдим итәбез. Алдыручылар һәм үземнең сезгә бер тәкъдимем (үтенечем) бар. Намаз вакытлары, бәйрәм вәгазьләре, котлаулары бик соңлап килә. Числоның 13 нче көнендә басылган газета 25 ендә, ә 26 сында басылганы алдагы айның 17 сендә генә килеп җитә. Мөкин булса, намаз вакытларын алдагы ай өчен число азагында, бәйрәм вәгазьләрен дә алданрак басуны сорар идек. Һәм язылучылар да күп булыр һәм без дә рәхмәтле булыр идек. Бөтен кеше дә мәчеткә йөрми, ә сораучылар күп.

Вәгаләйкүм әссәләм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтүһи!

**Наилә абыстай.**

## Яулык бәйләп йөрү ул мөслимә өчен горурлык

27 гыйнвар көнне телевизордан "Яулыклы мәктәп" тапшыруын карагач, кулыма каләм алырга булдым.

Бу тапшыруда төрле катлам хезмәткәрләре катнаштылар. Мине иң кызыксындырганы: "Мәктәптә укучы кыз балаларга яулык бәйләп йөрү кирәкме?"- дигәне булды. Ә нигә кирәк булмаска. Без ислам динендәге халык. Хатын-кызларыбыз яулыкны матур иттереп бәйләп куйсалар, бу үзенә күрә бер матур төсмер бирер, тәрбиянең беренче чарасы булыр иде. Хатын-кызларыбыз яулык бәйләп мөслимә булуларына горурлык хисе тойсалар, ул икенче яктан аларга әхлаклы, тәртипле булып үз-үзләрен кулда тотарга ярдәм итәр иде. Чөнки яулык бәйләү белән бит туташларыбыз, ханымнарыбыз үз өсләренә җаваплылык алалар. Кайчан күргәнегез бар түбәтәй кигән яшьләрнең, йә булмаса олы агайларның аракы эчеп, тәмәке тартып йөргәннәрен.

Телевизорны кабызып карасак, бернинди дә тәрбия чарасы булмаган фильмнар. Ә каян алырга соң ул чагында тәрбияне? Яулык бәйләп белем артмый, диючеләр дә бар. Эш аңарда түгел. Эш динебездәге, гореф-гадәтләребездәге кыйммәтләрне тәрбия эшендә куллану, балаларыбызны рухи яктан да сәламәт итеп тәрбияләү.

**Фәнис Нуретдинов,**
**Чаллы шәһәре.**

*Укучыларыбыз иҗаты*

## Комганга мәдхия

Һәрнәрсәнең бер моңы бар
Комганга да мәдхия;
Тәһарәт ала тәфсилләп
Баш кодагый Фәтхия.

Бисмилләсен кат-кат әйтеп
Су сала комганына;
Шөкер итеп дөньясының
Барына, булганына.

Зур корсаклы олы комган
Суны байтак сыйдыра;
Битне, кулны, аякларны
Пөхтә итеп юдыра.

Мич алдын бизәп утыра
Җиз ләгәнгә зур иптәш;
Тәһарәт алу башлана
Намаз вакыты җиткәч.

Иртә таңнан соң кичкәчә
Эш сәгате комганның;
Савабы күп, вакытында
Бит-күзләрне юганның.

Беркайчан чыкмый модадан
Мөселман өчен комган;
Кадимидән чисталыкка
Комган сәбәпче булган.

**Камил Шәмсуаров,**
**Баулы районы, Исергәп авылы**

# Намаз вакытлары

| Милади март | Көн исеме | Җөм.-ахир. Рәҗәб | Иртәнге намаз: Таң беленә | | | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | | | Кояш чыга | | | Зәвәл | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам | | | Ястү | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 1 | Чш | 2 | 06.06 | 04.20 | 04.33 | 06.36 | 04.52 | 05.05 | 08.06 | 06.22 | 06.35 | 13.28 | 11.42 | 11.55 | 13.38 | 12.00 | 12.00 | 16.54 | 15.06 | 15.19 | 18.50 | 17.04 | 17.17 | 20.29 | 18.45 | 18.58 |
| 2 | Пҗ | 3 | 06.04 | 04.17 | 04.30 | 06.34 | 04.50 | 05.03 | 08.04 | 06.20 | 06.33 | 13.27 | 11.42 | 11.55 | 13.37 | 12.00 | 12.00 | 16.56 | 15.08 | 15.21 | 18.52 | 17.06 | 17.19 | 20.31 | 18.47 | 19.00 |
| 3 | Җм | 4 | 06.01 | 04.14 | 04.27 | 06.31 | 04.47 | 05.00 | 08.01 | 06.17 | 06.30 | 13.27 | 11.42 | 11.55 | 13.37 | 12.00 | 12.00 | 16.58 | 15.10 | 15.23 | 18.54 | 17.08 | 17.21 | 20.33 | 18.49 | 19.02 |
| 4 | Шм | 5 | 05.59 | 04.12 | 04.25 | 06.29 | 04.45 | 04.58 | 07.59 | 06.15 | 06.28 | 13.27 | 11.42 | 11.55 | 13.37 | 12.00 | 12.00 | 16.59 | 15.12 | 15.25 | 18.56 | 17.10 | 17.23 | 20.35 | 18.51 | 19.04 |
| 5 | Як | 6 | 05.56 | 04.09 | 04.22 | 06.26 | 04.42 | 04.55 | 07.56 | 06.12 | 06.25 | 13.27 | 11.41 | 11.55 | 13.37 | 12.00 | 12.00 | 17.01 | 15.14 | 15.27 | 18.58 | 17.12 | 17.25 | 20.37 | 18.53 | 19.06 |
| 6 | Дш | 7 | 05.54 | 04.07 | 04.20 | 06.24 | 04.40 | 04.53 | 07.54 | 06.10 | 06.23 | 13.27 | 11.41 | 11.56 | 13.37 | 12.00 | 12.00 | 17.03 | 15.15 | 15.28 | 19.00 | 17.14 | 17.27 | 20.39 | 18.55 | 19.08 |
| 7 | Сш | 8 | 05.51 | 04.04 | 04.17 | 06.21 | 04.37 | 04.50 | 07.51 | 06.07 | 06.20 | 13.26 | 11.41 | 11.54 | 13.36 | 12.00 | 12.00 | 17.05 | 15.17 | 15.30 | 19.02 | 17.16 | 17.29 | 20.41 | 18.57 | 19.11 |
| 8 | Чш | 9 | 05.49 | 04.01 | 04.14 | 06.19 | 04.34 | 04.48 | 07.49 | 06.04 | 06.18 | 13.26 | 11.41 | 11.54 | 13.36 | 12.00 | 12.00 | 17.06 | 15.19 | 15.32 | 19.04 | 17.18 | 17.31 | 20.43 | 18.59 | 19.13 |
| 9 | Пҗ | 10 | 05.46 | 03.59 | 04.12 | 06.16 | 04.32 | 04.45 | 07.46 | 06.02 | 06.15 | 13.26 | 11.41 | 11.54 | 13.36 | 12.00 | 12.00 | 17.08 | 15.21 | 15.34 | 19.06 | 17.20 | 17.33 | 20.45 | 19.02 | 19.15 |
| 10 | Җм | 11 | 05.44 | 03.56 | 04.09 | 06.14 | 04.29 | 04.42 | 07.44 | 05.59 | 06.12 | 13.25 | 11.40 | 11.53 | 13.35 | 12.00 | 12.00 | 17.10 | 15.22 | 15.35 | 19.08 | 17.22 | 17.35 | 20.47 | 19.04 | 19.17 |
| 11 | Шм | 12 | 05.41 | 03.53 | 04.06 | 06.12 | 04.27 | 04.40 | 07.42 | 05.57 | 06.10 | 13.25 | 11.40 | 11.53 | 13.35 | 12.00 | 12.00 | 17.11 | 15.24 | 15.37 | 19.10 | 17.24 | 17.37 | 20.49 | 19.06 | 19.19 |
| 12 | Як | 13 | 05.38 | 03.50 | 04.03 | 06.09 | 04.24 | 04.37 | 07.39 | 05.54 | 06.07 | 13.25 | 11.40 | 11.53 | 13.35 | 12.00 | 12.00 | 17.13 | 15.26 | 15.39 | 19.12 | 17.26 | 17.39 | 20.52 | 19.08 | 19.21 |
| 13 | Дш | 14 | 05.35 | 03.48 | 04.01 | 06.07 | 04.22 | 04.35 | 07.37 | 05.52 | 06.05 | 13.25 | 11.39 | 11.53 | 13.35 | 12.00 | 12.00 | 17.15 | 15.28 | 15.41 | 19.14 | 17.28 | 17.42 | 20.54 | 19.10 | 19.24 |
| 14 | Сш | 15 | 05.33 | 03.45 | 03.58 | 06.04 | 04.19 | 04.32 | 07.34 | 05.49 | 06.02 | 13.24 | 11.39 | 11.52 | 13.34 | 12.00 | 12.00 | 17.16 | 15.29 | 15.42 | 19.16 | 17.30 | 17.44 | 20.56 | 19.13 | 19.26 |
| 15 | Чш | 16 | 05.30 | 03.42 | 03.55 | 06.01 | 04.16 | 04.30 | 07.31 | 05.46 | 06.00 | 13.24 | 11.39 | 11.52 | 13.34 | 12.00 | 12.00 | 17.18 | 15.31 | 15.44 | 19.18 | 17.33 | 17.46 | 20.58 | 19.15 | 19.28 |
| 16 | Пҗ | 17 | 05.27 | 03.39 | 03.52 | 05.59 | 04.14 | 04.27 | 07.29 | 05.44 | 05.57 | 13.24 | 11.39 | 11.52 | 13.34 | 12.00 | 12.00 | 17.19 | 15.33 | 15.46 | 19.20 | 17.35 | 17.48 | 21.00 | 19.17 | 19.30 |
| 17 | Җм | 18 | 05.24 | 03.36 | 03.49 | 05.56 | 04.11 | 04.24 | 07.26 | 05.41 | 05.54 | 13.23 | 11.38 | 11.51 | 13.33 | 12.00 | 12.00 | 17.21 | 15.34 | 15.47 | 19.22 | 17.37 | 17.50 | 21.02 | 19.19 | 19.33 |
| 18 | Шм | 19 | 05.21 | 03.33 | 03.46 | 05.54 | 04.09 | 04.22 | 07.24 | 05.39 | 05.52 | 13.23 | 11.38 | 11.51 | 13.33 | 12.00 | 12.00 | 17.23 | 15.36 | 15.49 | 19.24 | 17.39 | 17.52 | 21.04 | 19.22 | 19.35 |
| 19 | Як | 20 | 05.19 | 03.30 | 03.43 | 05.51 | 04.06 | 04.19 | 07.21 | 05.36 | 05.49 | 13.23 | 11.38 | 11.51 | 13.33 | 12.00 | 12.00 | 17.24 | 15.38 | 15.51 | 19.26 | 17.41 | 17.54 | 21.07 | 19.24 | 19.37 |
| 20 | Дш | 21 | 05.16 | 03.27 | 03.40 | 05.49 | 04.03 | 04.17 | 07.19 | 05.33 | 05.47 | 13.23 | 11.37 | 11.51 | 13.33 | 12.00 | 12.00 | 17.26 | 15.39 | 15.52 | 19.28 | 17.43 | 17.56 | 21.09 | 19.26 | 19.39 |
| 21 | Сш | 22 | 05.13 | 03.24 | 03.37 | 05.46 | 04.01 | 04.14 | 07.16 | 05.31 | 05.44 | 13.23 | 11.37 | 11.50 | 13.33 | 12.00 | 12.00 | 17.27 | 15.41 | 15.54 | 19.30 | 17.45 | 17.58 | 21.11 | 19.29 | 19.42 |
| 22 | Чш | 23 | 05.10 | 03.21 | 03.34 | 05.44 | 03.58 | 04.11 | 07.14 | 05.28 | 05.41 | 13.22 | 11.37 | 11.50 | 13.32 | 12.00 | 12.00 | 17.29 | 15.42 | 15.55 | 19.32 | 17.47 | 18.00 | 21.13 | 19.31 | 19.44 |
| 23 | Пҗ | 24 | 05.07 | 03.18 | 03.31 | 05.41 | 03.56 | 04.09 | 07.11 | 05.26 | 05.39 | 13.22 | 11.37 | 11.50 | 13.32 | 12.00 | 12.00 | 17.30 | 15.44 | 15.57 | 19.34 | 17.49 | 18.02 | 21.16 | 19.33 | 19.46 |
| 24 | Җм | 25 | 05.04 | 03.15 | 03.28 | 05.39 | 03.53 | 04.06 | 07.09 | 05.23 | 05.36 | 13.22 | 11.36 | 11.50 | 13.32 | 12.00 | 12.00 | 17.32 | 15.46 | 15.59 | 19.36 | 17.51 | 18.04 | 21.18 | 19.36 | 19.49 |
| 25 | Шм | 26 | 05.01 | 03.11 | 03.24 | 05.36 | 03.50 | 04.03 | 07.06 | 05.20 | 05.33 | 13.21 | 11.36 | 11.49 | 13.31 | 12.00 | 12.00 | 17.33 | 15.47 | 16.00 | 19.38 | 17.53 | 18.06 | 21.20 | 19.38 | 19.51 |
| 26 | Як | 27 | 04.58 | 03.08 | 03.21 | 05.34 | 03.48 | 04.01 | 07.04 | 05.18 | 05.31 | 13.21 | 11.36 | 11.49 | 13.31 | 12.00 | 12.00 | 17.35 | 15.49 | 16.02 | 19.40 | 17.55 | 18.08 | 21.22 | 19.40 | 19.54 |
| 27 | Дш | 28 | 04.55 | 03.05 | 03.18 | 06.41 | 03.45 | 03.58 | 07.01 | 05.15 | 05.28 | 13.21 | 11.35 | 11.49 | 13.31 | 12.00 | 12.00 | 17.36 | 15.50 | 16.03 | 19.42 | 17.57 | 18.10 | 21.25 | 19.43 | 19.56 |
| 28 | Сш | 29 | 04.51 | 03.02 | 03.15 | 05.29 | 03.43 | 03.56 | 06.59 | 05.13 | 05.26 | 13.20 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.38 | 15.52 | 16.05 | 19.43 | 17.59 | 18.12 | 21.27 | 19.45 | 19.59 |
| 29 | Чш | 1 | 04.48 | 02.58 | 03.11 | 05.26 | 03.40 | 03.53 | 06.56 | 05.10 | 05.23 | 13.20 | 11.35 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.39 | 15.53 | 16.06 | 19.45 | 18.01 | 18.14 | 21.29 | 19.48 | 20.01 |
| 30 | Пҗ | 2 | 04.45 | 02.55 | 03.08 | 05.24 | 03.37 | 03.50 | 06.54 | 05.07 | 05.20 | 13.20 | 11.34 | 11.48 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.41 | 15.55 | 16.08 | 19.47 | 18.03 | 18.16 | 21.32 | 19.50 | 20.04 |
| 31 | Җм | 3 | 04.42 | 02.52 | 03.05 | 05.21 | 03.35 | 03.48 | 06.51 | 05.05 | 05.18 | 13.20 | 11.34 | 11.47 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 17.42 | 15.56 | 16.09 | 19.49 | 18.05 | 18.18 | 21.34 | 19.53 | 20.06 |

## Төзәтмә

Газетабызның 2 нче санындагы “Хаҗга автомашинада” язмасында верстка вакытында текстның бер өлеше төшеп калган. Икенче багананың өстендә булырга тиешле текст түбәндәгечә: “... эчендә юлга кузгалдык. Юлга карта алдылар, янәсе, кыска юл белән барабыз, тизрәк барып җитәбез. Оренбург аркылы киттек, Казахстанга җиттек. Актүбәдә мәчеттә туктап шунда кундык. Андагы имам сораштырды, ничек, каян барасыз? дип. Сөйләп биргәч: “Анда җул җук,”- диде. Безнекеләр: “Ничек инде федеральный трасса булып юл булмасын,”- дип тыңламыйча киттек. Дөрестән дә, 500 чакрым юлны көне буе бардык. СССР вакытында төзелгән юллар бөтенләй ватылып беткән икән. Кулсара шәһәренә килеп җиттек. Анда безне мәчет имамы өенә алып кайтып хөрмәт итте. Ирләр мәчеттә, мин имамның өендә кундык. Барганда 8 ир-атка мин берүзем идем хатын-кызлардан. Ике машина белән юлга чыктык. Иртән кузгалып киттек. Икенче машинаның тәгәрмәчен карарга кирәк иде. Мастерской булмасмы? дип..”

Шуннан соң икенче баганадагы текст башлана.

Автордан һәм укучыларыбыздан гафу үтенәбез.

## “Ислам нуры” кибете чакыра

Дини әдәбият, календарьлар, Коръән ( төрле басмада, шул исәптән электрон вариантта), түбәтәйләр, бай ассортиментта хиҗаблар, яулыклар, шәмаилләр, сувенирлар, Исламча яшәү рәвешендә кирәк булган башка әйберләр, “Ислам нуры” нәшриятында дөнья күргән яңа китаплар. Биредә шулай ук “Ислам нуры” газетасын сатып алырга була.

Кибет иртәнге 9 дан кичке 16 сәгатькә кадәр эшли. Шимбә көнне 9 дан 13 сәгатькә кадәр. Якшәмбе — ял. Адресы: Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Үзәк ур., 72 ( “Тәүбә” мәчетенә җитәрәк). Тел. 89874127845.

## Кабер ташлары, чардуганнар ясыйбыз

Бәясе 3 мең сумнан башлана. Срогы — бер атна. Эш көннәрендә иртәнге 9 дан кичке 5 кә кадәр, шимбә иртәнге 9 дан көндезге 2 гә кадәр (якшәмбе ял) түбәндәге адрес буенча мөрәҗәгать итәргә: Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Үзәк ур., 70 Тел. (8552) 36-62-04.

**Нәшире**
**Иршат Гыйльметдин улы ШӘЙХАТТАР**

**Баш мөхәррире**
**Хәлил ШӘРИФ**

**Тел.:** (8552) 70-51-09
**Факс:** (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, “Ислам нуры” дини эшмәкәрлек Үзәге

Газетабыз мәкаләләрен күчереп басканда аларның “Ислам нуры”ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен:**
**e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучылар сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җаваплар бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

“Роспечать” агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1300.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, алай дабулмаса башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. “Ислам нуры”ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетабызны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән “Ислам нуры” басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды:**
**график буенча**
**13 февраль 16 сәг.,**
**фактта 13 февраль 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**